ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

8 июль, 2016 ел № 9/4

Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы
сызымына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы сызымына үзгәрешләр кертү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен карап тикшергәч, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24 маддәсе, Россия Федерациясе Җир кодексының 84 маддәсе, «Магистраль торбалар» СНиП 2.05.06-85 таләпләре, шәһәр Уставының 19 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең 2006 елның 27 июнендәге 14/4 санлы Карары (Шәһәр Советының 2014 елның 9 декабрендәге 35/11, 2016 елның 24 февралендәге 6/11 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы сызымына, торак пункт җирләреннән сәнәгать территорияләрен чыгару өлешендә, кушымтадагыча үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының шәһәр төзелеше, шәһәр инфраструктурасын һәм торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
9/4 нче Карарына
кушымта
8 июль, 2016 ел

# Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы сызымы

Яр Чаллы шәһәренең Генераль планы сызымына үзгәрешләр кертү
(«Транснефть-Прикамье» АҖ объекты буенча халык яши торган пункт чикләрен үзгәртү өлешендә)

